ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

20.11.2019 Казан шәһәре № 10-89/кс

2020 елга «Үзәк торак-коммуналь идарәсе» федераль дәүләт бюджет учреждениесе өчен агынты суларны транспортлауга тарифлар билгеләү хакында

«Су белән тәэмин итү һәм су агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Салкын су белән тәэмин итү һәм су агызу өлкәсендә тарифларны дәүләти җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм су агызу өлкәсендә җайга салынулы тарифларны хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Су агызуны гамәлгә ашыручы «Үзәк торак-коммуналь идарәсе» федераль дәүләт бюджет учреждениесе өчен агынты суларны транспортлауга әлеге карар кушымтасы нигезендә, календарь буенча бүлеп, тарифлар билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2020 елның 1 гыйнварыннан 2020 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә булачак.

3. Су агызуны гамәлгә ашыручы «Үзәк торак-коммуналь идарәсе» федераль дәүләт бюджет учреждениесенә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 17 гыйнварындагы 6 номерлы карары белән расланган су белән тәэмин итү һәм су бүлү өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартларына туры китереп, ирекле файдаланылырга тиешле мәгълүматны чираттагы җайга салу чорына тарифлар билгеләү турындагы карар кабул ителгән көннән башлап 30 календарь көненнән соңга калмыйча ачарга.

4. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы А.Л.Штром

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 20.11.2019 № 10-89/кс карарына кушымта

Су агызуны гамәлгә ашыручы «Үзәк торак-коммуналь идарәсе» федераль дәүләт бюджет учреждениесе өчен 2020 елга агынты суларны транспортлауга календарь буенча бүленгән тарифлар

| № т/с | Муниципаль берәмлекнең, салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) су агызуны гамәлгә ашыручы оешманың аталышы | Агынты суларны транспортлаган өчен тариф (бер ставкалы), сум/куб.м | |
|---|---|---|---|
| | | 01.01.2020 башлап 30.06.2020 кадәр | 01.07.2020 башлап 31.12.2020 кадәр |
| | «Казан шәһәре» муниципаль берәмлеге | | |
| 1 | «Үзәк торак-коммуналь идарәсе» федераль дәүләт бюджет учреждениесе (тарифлар НДС башка күрсәтелгән) | 7,08 | 9,25 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге